Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл Советы

КАРАРЫ

12 декабрь 2024 ел № 104

Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл Советының 2018 елның 24 августындагы 51 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 25 сентябрендәге 829 номерлы «Татарстан Республикасында депутатларның, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә

Сөләй авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл Советының 2018 елның 24 августындагы 51 номерлы «Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары турында» карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл Советының 2018 елның 5 декабрендәге 60 нчы номерлы,2020 елның 11 декабрендәге 11 нче номерлы, 2022 елның 27 октябрендәге 53 нче номерлы, 2022 елның 14 декабрендәге 58 нче номерлы, 2024 елның 26 июнендәге 96 нчы номерлы) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарга 1 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлегенең муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Вазыйфаи оклад (11 группа хезмәткә түләү) |
| --- | --- |
| Башкарма комитет җитәкчесе | 20 985 |

| | |
|---|---|
| Башкарма комитет җитәкчесенең урынбасары | 20 566» |

1.2. карарга 2 нче кушымтадагы таблицаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлмәт муниципаль районы Сөләй авыл җирлегенең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарәнең сайлаулы вазыйфаи затларының ай саен акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфаның исеме | Ай саен акчалата бүләкләү күләме (11 группа хезмәткә түләү) |
|---|---|
| Башлык | 20 991 |
| Башлык урынбасары | 15 085» |

2. Әлеге карарны Әлмәт районы, Сөләй авылы, Совет урамы, 53а йорты; Урсалабаш авылы, Әхмәдуллин урамы, 114а йорты; Яңа Михайловка авылы, Заречная урамы, 29а йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда халыкка игълан итәргә, шулай ук Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнвареннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Сөләй авыл
җирлеге башлыгы А.З.Бикбаев